| ГОСУДАРСТВЕННЫЙ КОМИТЕТ РЕСПУБЛИКИ ТАТАРСТАН ПО ТАРИФАМ | | ТАТАРСТАН РЕСПУБЛИКАСЫНЫҢ ТАРИФЛАР БУЕНЧА ДӘҮЛӘТ КОМИТЕТЫ |
|---|---|---|

**ПОСТАНОВЛЕНИЕ** **КАРАР**

14.12.2023 г. Казань № 599-65/кс-2023

2024 елга Югары Ослан муниципаль районының «Волжанка» муниципаль унитар предприятиесе өчен эчәргә яраклы суга тарифлар билгеләү хакында

«Су белән тәэмин итү һәм ташландык су агызу турында» 2011 елның 7 декабрендәге 416-ФЗ номерлы федераль закон, Россия Федерациясе Хөкүмәтенең «Салкын су белән тәэмин итү һәм ташландык су агызу өлкәсендәге тарифларны дәүләт тарафыннан җайга салу турында» 2013 елның 13 маендагы 406 номерлы карары, Федераль тарифлар хезмәтенең «Су белән тәэмин итү һәм ташландык су агызу өлкәсендә җайга салынулы тарифларны хисаплау буенча методик күрсәтмәләр раслау турында» 2013 елның 27 декабрендәге 1746-э номерлы боерыгы, Татарстан Республикасы Министрлар Кабинетының 2010 елның 15 июнендәге 468 номерлы карары белән расланган Татарстан Республикасының Тарифлар буенча дәүләт комитеты турында нигезләмә, Татарстан Республикасы Тарифлар буенча дәүләт комитеты идарәсенең 14.12.2023 № 58-ПР утырыш беркетмәсе нигезендә Татарстан Республикасы Тарифлар буенча дәүләт комитеты КАРАР БИРӘ:

1. Салкын су белән тәэмин итүне гамәлгә ашыручы Югары Ослан муниципаль районының «Волжанка» муниципаль унитар предприятиесе (алга таба – «Волжанка» МУП) өчен эчәргә яраклы суга әлеге карар кушымтасы нигезендә календарь бүленгән тарифлар билгеләргә.

2. Әлеге карарның 1 пунктында билгеләнгән тарифлар 2024 елның 1 гыйнварыннан 2024 елның 31 декабренә кадәр гамәлдә була.

3. Салкын су белән тәэмин итүне гамәлгә ашыручы «Волжанка» МУП иректе файдаланылырга тиешле мәгълүматны Россия Федерациясе Хөкүмәтенең 2023 елның 26 гыйнварындагы 108 номерлы карары белән расланган Су белән тәэмин итү һәм ташландык су агызу өлкәсендә мәгълүмат ачу стандартлары нигезендә, чираттагы җайга салу чорына тарифлар билгеләү турында карар кабул ителгән көннән башлап 30 көннән соңга калмыйча ачарга.

4. Бу карар рәсми басылып чыккан көненнән башлап 10 көн узгач үз көченә керә.

Рәис А.С.Груничев

Татарстан Республикасы Тарифлар
буенча дәүләт комитетының
14.12.2023 № 599-665/кс-2023
карарына кушымта

Салкын су белән тәэмин итүне гамәлгә ашыручы «Волжанка» МУП өчен эчәргә яраклы суга 2024 елга календарь буенча бүленгән тарифлар

| т/с | Муниципаль берәмлекнең, салкын су белән тәэмин итүне һәм (яки) су агызуны гамәлгә ашыручы оешманың аталышы | Эчә торган суга тариф (бер ставкалы), сум/куб.м | |
|---|---|---|---|
| | | 01.01.2024 башлап 30.06.2024 кадәр | 01.07.2024 башлап 31.12.2024 кадәр |
| | Югары Ослан муниципаль районы | | |
| 1 | «Волжанка» МУП*, технологик яктан үзара бәйләнмәгән үзәкләштерелгән берничә система булуына карап, тарифларны дифференциацияләү: | | |
| 1.1 | Яр буе Морквашы авыл җирлеге кулланучылары | 25,55 | 41,67 |
| 1.2 | Олы Мәми, Борнаш, Вахитов, Введенский Бистәсе, Килди, Карагуҗа, Куралово, Мәйдан, Яңа Рус Мәмәтхуҗасы, Октябрь, Соболевский, Шылаңгы авыл җирлекләре кулланучылары | 34,52 | 41,67 |

<*>Салым салуның гадиләштерелгән системасын куллана.

Татарстан Республикасы Тарифлар буенча дәүләт
комитетының тариф карарларын кабул итүне оештыру,
контрольдә тоту һәм теркәү бүлеге